*Единство в многообразии*

# Ф И К Е Р

**Орган Казахстанского конгресса татар и башкир**

**№4 (117) 2018 ел**

**Газета «Фикер» выходила в 1905-1907 гг. при участии Габдуллы Тукая. С 1993 г. выходит в г. Алматы: с 2000 г. под названием «Фикер-Өмет», с 2013 г.«Фикер».**

## АСТАНА ШӘҺӘРЕНДӘ 2018 ЕЛНЫҢ 28 АПРЕЛЕНДӘ КАЗАКЪСТАН ХАЛКЫ АССАМБЛЕЯСЕНЕҢ ЧИРАТТАГЫ СЕССИЯСЕ ҮТКӘРЕЛӘЧӘК





## АЯЗ МИРСӘЕТ улы ГЫЙЛӘҖЕВ

## (1928-2002)

Атаклы прозаик һәм драматург, публицист һәм тәнкыйтьче Аяз Гыйләҗев Татарстанның Сарман авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килгән. Урта мәктәпне уңышлы тәмамлап, Аяз колхозда эшли, аннары Зәй районының комсомол комитетында бүлек мөдире була.

1948 елда ул Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тиздән әдәбият түгәрәгенә йөри башлый, шунда аның беренче әдәби тәҗрибәләрекүренә. Яшь егет иҗтимагый эшләрдә дә актив катнаша, студентларның агитация-пропаганда төркеме составында була. Каникуллар вакытында Татарстанның районнарында бу төркем концертлар куя, әдәби кичәләр оештыра.

Ләкин Аяз Гыйләҗевнең студент тормышы 1950 елда киселә: югары уку йортларында укучы бер төркем татар студентларын «советка каршы коткы таратуда һәм милләтчелектә» гаепләнеп, кулга алалар. Ябык суд утырышы Аязны җиде ел төрмәдә утыруга хөкем итә. Аны Караганда шәһәрендәге лагерьга җибәрәләр. Булачак язучының озакка сузылган биш ел гомере шул лагерьда уза. Тик 1955 елда гына Аяз Гыйләҗев азат ителә һәм реабилитацияләнә.

Казанга кайтып, ул бүленгән укуын университетта дәвам итә. Озак та үтми, Аяз Гыйләҗев «Чаян», «Азат хатын» журналлары белән хезмәттәшлек итә башлый. Язучы укучыларга таныла. Аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына эшкә чакыралар. Ул монда проза бүлегенең редакторы булып эшли. 1961 елда Аяз Гыйләҗевнең «Дүртәү» исемле беренче повесте басылып чыга. Шул ук елда ул Татарстан язучылар берлегенә әгъза булып кабул ителә.

1963 елда Аяз Гыйләҗев СССР ның Язучыдар берлеге янындагы икееллык Югары әдәби курсларны тәмамлый һәм профессионал язучы булып китә. Ул күп санлы мәкаләләр, очерклар,фельетоннар, хикәяләр, пьесалар, повестьлар, романнар авторы. Аның әсәрләре рус теленә, төрек теленә һәм башка байтак телләргә тәрҗемә ителгән.

Аяз Гыйләҗевнең комедияләре, трагедияләре, драмалары Казан, Әлмәт, Чаллы, Минзәлә театрларында куела, башка телләргә тәрҗемә ителгән пьесалары рус, бшкорт, чуваш, авар милли театрлар сәхнәләрендә урын алган. Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин Аяз Гыйләҗевнең үзен һәм аның иҗатын түбәндәгечә бәяләгән иде: «Аяз кешеләр белән аралашуда бик таләпчән иде, аның тормышка үз карашы бар иде. Дөньяда күпне күргән, тормышның бөтен үзенчәлекләрен белгән кеше иде. Аның «Өч аршын җир» повесте, һичшиксез, татар әдәбиятының алтын фондына керәчәк».

Милләттәшебез Аяз Гыйләҗевнең әдәби хезмәте югары бәяләнде: ул Татарстанның халык язучысы исеменә лаек булды, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе иде. Аяз Гыйләҗев Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә(Татарстан), Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премиягә (Татарстан) һәм Максим Горький исемендәге дәүләт премиясенә (Россия) ия булды.

Язучының 90 еллык юбилее быел Татарстанда киң билгеләнде.

# ТАТАРНЫҢ МИЛЛИ КЫҢГЫРАВЫ

Аяз Гыйләҗевнең таланты татар әдәбиятының бөтен жанрларында да киң ачыла: ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, оста публицист, очеркист һәм, әлбәттә, үткен тәнкыйтьче буларак танылa. Татарстанның халык язучысы, Татарстанның Г. Тукай һәм РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты, Татарстанның, Россиянен атказанган сәнгать эшлеклесе А.М. Гыйләҗевнең ижади мирасы хаклы рәвештә XX-XXI гасыр татар әдәбиятының иң кыйммәтле хәзинәсе, әдәби-мәдәни байлыгы булып санала, чөнки ул – әдәби дәверне яңарыш чорына алып кергән, милли үзаңны, фикер күтәрелешен әзерләгән, яшәү мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән әдип. Анын дистә еллар дәвамында тудырылган гажәеп кин кырлы, күп катламлы, жанр төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай әдәби ижаты XX гасыр татар тормышының ижади елъязмасы булып укыла, милли әдәбиятнын гына түгел, дөнья әдәбиятының да бер өлеше булып тора.

Ул әдәбиятка житлеккән шәхес буларак, сыналган тормыш позицияләре, төптән уйланган ижади принциплары белән килеп керде. Анын артында Казан университетының филология факультетында, Мәскәүдәге Өлкән әдәби курсларында уку гына түгел, ә крестьяннарның гасырлар буенча салынган яшәү ревешен сындырып алып барылган коллективлаштыру, халыкка коточкыч сынаулар алып килгән Бөек Ватан сугышы, А.Гыйләҗевнең сүзләре белән әйткәндә, аннан язучы ясаган төрмә һәм лагерьдагы тормышы да бар.

Язучы әдәбиятка бөек Ватан сугышыннан соңгы унъеллыкта – «сәнгать өстеннән идеологик басым моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә көчәйгән дәвердә» килеп керә.“Мин әдәбиятка килгән чор – ачык, җете төсләр белән балкыган вакыт! Мин китапларыма авыр сталинизм чорыннан соң килеп кердем. Безнең барабызны да “илдә бер генә бөек кеше бар, ул кояш, ул нур, ул акыл яисе, ул мәңгелек, ул барыбыз өчен дә уйлый ала, ул алла, аллалардан да бөегрәк!” дип өйрәттеләр, шуңа көчләп ышандырдылар, башкача уйлау сәләтен калдырмадылар...”. Ләкин язучы «соры, уртакул әдәби» агымга кушылмый, ижат программасын булдыра: «Мин бөтен гомеремне бер ачык максатка юнәлтергә тырыштым, кеше күңеленең хөрлегенә дан җырладым, кешеләрнең иелгән башларын аз гына булса да югарырак күтәрергә тырыштым! Аз гына калкынырга, калкынырга... Күккә карарга өйрәнәргә, күктә Киек каз юлы барлыгын белергә, белергә дә сокланырга, җирдә бәхет барын онытмаска, кешеләрнең винтик түгеллеген тәшендерергә, аларга якынаерга омтылдым”. Үз заманының идеологик басымына җаны-тәне белән каршы әдип чордашларын системаның винтиклары булмаска, көрәшергә, гамәлләрне мәңгелек кыйммәтләр бизмәне белән үлчәргә чакыра. Әсәрләрендә төп әхлакый проблемаларны яктыртканда, әдип гүя башка заман күзлегеннән бәяли, кыйммәтләр югалуына сызлана. Әдипнең проза һәм драматургиясе бер иҗат методы, әхлак кануннары белән бәйләнгән бер әдәби дөньяга әверелә. Иҗади эчәнлеге дәвамында А. Гыйләҗев әдәбият үсешенә зур өлеш кертә, 40 артык пьеса, 6 роман, 17 повесть, дистәлегән хикәяләр, мәкаләләр иҗат итә.

А. Гыйләҗев иҗаты – татар халкы хөрмәтенә куелган мәдәни һәйкәл ул. Әдип үз әсәрләрендә татар милләтенең семиосфера парадигмасын булдыруга ирешә. Анын фикеренчә, безнең иҗат әһелләре дөньяның төрле почмакларына сибелгән һәр татар кешесе күңелендә милли хисләр уятырга, аларны берләштерергә бу- рычлы. Милләт бердәм булсыи өчен, тел, дин – уртак, халыкның торган җире бер булу кирәк, дип саный ул.




***Минтимер Шәймиев һәм Аяз Гыйләҗев***

Әдип «лингвистик миллилек» теориясен дә тулысынча яклый. Бу теориянең төп тезисы буенча, «һәр милләтнең тарихи рухын белдерә торган үзенә хас теле һәм әдәби мәдәнияте бар». Шушы фикергә бәйле рәвештә ул милли кодлар, милли мәгънәләр формаланггыру һәм тәкъдим итүдә әдәбиятның хәлиткеч ролен таный. Милли рухны гәүдәләндерүче мәдәният әһеле булуны исә үзенә максат итеп куя. XX йөз башы традицияләрен кабул итеп, әдәбиятны татар халкының милли горурлыгы булырлык дәрәҗәгә күтәрергә тел и, язма-басма сүзне милли мәдәниятнең нигезе дип саный. Халык җырларындагы, легенда-мифларындагы вакыт сынавын үткән архетипик сюжетлар ярдәмендә әдип «милләт идеясе»н ныгыта һәм үз укучысына җиткерә.

А. Гыйләҗев иҗатында милләтебез тарихының Болгар дәүләте төзелү, ислам дине кабул ителү, Казан ханлыгы җимерелү, мөһаҗирләр язмышы кебек төи сәхифәләре җанлы чагылыш таба. Ул татарлар үзләрен бердәм, бербөтен итеп хис иткән тарихи вакыйгаларны игътибар үзәгенә куя. Тарихи образ көченә ихластан ышана, милләтнең үткәне белән бәйле вакыйгаларны халык хәтерендә тергезеп, татар халкының бүгенге җәмгыятьтә урынын ныгыту, дәүләтчелекне кайтару турында уйлана. Милли тарих һәм халык язмышын бер үремтәдә тасвирларга омтыла. Каләмдәшләренә «татар җирен Казан арты белән генә чикләргә ярамый» дип, гел искәртеп торган язучы үзе дә иҗатында Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары тарихына һәрдаим мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә аның әсәрләрендә «туган җир» мифологемасы Идел-йорт буларак кабул ителә. Милли характер туган җирдә генә саклана ала, дип саный әдип. Ул кулланган топонимнар да милли мәгънә тудыруга этәргеч булып торалар.

А. Гыйләҗев — әдәбиятыбызда татар милли характерын булдыруга зур көч куйган әдип. Без белгән Мирвәли, Шәмсегаян (“Өч аршын җир”), Әдилә, Сабираттәй (“Язгы кәрваннар”), Бибинур (“Җомга көн, кич белән...”), Галикәй, Хәйретдин агайлар (“Әтәч менгән читәнгә”) – бары тик татар дөньясында гына була алган, шул дөньяның үзенә генә хас үзенчәлекләрен туплаган бөек шәхесләр. Аларның батырлыгы, кешелеклеге язучыга якты маяк булып торган, җанына мәңге сүнмәс җылылык биргән.

Язучы үткәндәге һәм бүгенге көн милләт хадимнәренең тулы җыелмасын тудыруны да максат итә: «Аерым кешенең хәтере ялгыз агач ул, аны үтмәс балта белән дә кисеп ташлап була. Халык хәтере мәгъриур карурман шикелле, кисеп чыксаң — орлыктан шытачак, яндырып узсаң — тамырдан калкачак. Урманның гомерен йөзәр яшьлек имәннәр ныгыткан кебек, халык хәтерен ныгыта, оештыра торган уртак хәзинәләр кирәк. Сәйдәшләр, Тукайлар, Мусалар».

Әдәбиятыбызның классигы халкыбызның көйгә-җайга салынган көндәлек тормышында данлый, Сабантуй, Җыен, Ураза, Корбан бәйрәме, җомга, орлык чыгару һәм башка шундый йола-гадәтләрнең тыныч-бәхетле тормышның нигезе булуын раслый.

А.М. Гыйләҗев иҗатында көндәлекләр һәм хатлар аерым урын алып торалар. 2001 елда, үзенең шәхси архивын бер системага китергәндә, ул болай дип яза: "Минем архивымда ун меңнәрчә хат саклана. Күпчелеге – үзем язган хатлар. ... Минем чынлыгым, бар булганым – халкыма булган тирән мәхәббәтем – шул хатлар аша киләчәккә дә барып җитәр дип ышынып яшим".

А.Гыйләҗев беренче көндәлекләрен мәктәп елларында ук яза башлый. Әкренләп әлеге язмалар аның әдәби мирасының аерылгысыз бер өлешенә әверелә. Аларда язучының үсеше, тормыш хакындагы уйланулары, иҗтимагый-әхлакый эзләнүләре чагылыш таба. 1980 елдан исә көндәлекләрнең эчтәлеге үзгәрә: язучы «үз заманының протоколчысы»на әверелә. Кызыксыну даирәсен әдәбият һәм гаилә белән генә чикләмичә, тормышның башка төрле якларына да игътибар итә. Укыган китаплары, газета-журналлардагы мәкаләләре, караган сиектакль-фильмнары, акыллы фикердәшләр белән очрашулары, тормышындагы вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр хакында яза. Аны фәнни ачышлар, бигрәк тә татар халкы вәкилләренең теге яки бу олкәдәге уңышлары кызыксындыра. А. Гыйләҗев илдә һәм дөньяда барган сәяси вакыйгаларны күзәтеп, теркәп бара, хөкүмәтнең һәм оипозицион көчләрнең гамәлләрен бәяли, үз-үзенә, иҗатына хисап бирә, киләчәккә булган планнарын барлый. Тора-бара Гыйләҗевләр шәҗәрәсен төзү максатында нәсел тарихы белән дә кызыксына. Урыны белән аерым язмалар әдәби портретлар һәм некрологлар төсен ала. А. Гыйләҗев замандашларының исемнәрен мәңгеләштерергә, киләчәк буыннарга аларның кабатланмас характер сыйфатларын, үзенчәлекле карашларын җиткерергә, иҗатларына булган мөнәсәбәтен динамикада сурәтләргә омтыла. Көндәлекләрдә шулай ук туган як табигатенә, туган илгә мәдхия булып торган поэтик сурәтләүләр дә урын ала. 1992-1997 елларда көндәлек алып бару А. Гыйләҗевнең бурычына, кыйммәтле шәхси актына әверелсә дә, алга таба әдип, авырып китү сәбәпле, язмаларны мөстәкыйль рәвештә теркәп бара алмый башлый...

Соңгы биш ел эчендә Татарстан Республикасында һәм чит илләрдә бөек язучының исемен мәңгеләштерү буенча зур эш башкарылды:

- 6 томда А. Гыйләҗевнең "Сайланма әсәрләре" дөнья күрде, бу исә язучының хатларын, көндәлекләрен, публицистикасын, әлегәчә дөнья күрмәгән әсәрләрен һәм әсәрләрнең вариантларын фәнни әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирде;
- А. Гыйләҗевнең йомгаклау романы булган "Йәгез, бер дога!" әсәре бер ел эчендә өч телдә: татар, рус һәм мадъяр телләрендә басылып чыкты. Бу басмаларны тәкъдим итү кичәләре Татарстанда да, Венгриядә дә үткәрелде;
- татар телендә А. Гыйләҗевнең "Өтәч менгән читәнгә" повестьлар җыентыгы "Татар прозасы" сериясендә басылды;



***Аяз Гыйләҗев коллегалары белән***

- рус телендә А. Гыйләҗевнең “При свете зарниц” повестьлар җыентыгы яңадан басылды (бу җыентык өчен әдип 1987 елда Россиянең Югары әдәби премиясенә лаек булган иде);
- язучының “Өч аршын җир”, “Җомга көн, кич белән...”, “Яра” повестьлары, төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрде;
- “Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәя”, “Язгы кәрваннар”, “Берәү” әсәрләре исә, төрек теленә тәрҗемә ителеп, үз чиратларын көтәләр;
- «Яра» повесте да, рус теленә тәрҗемә ителеп, басмага әзер;
- әдипнең күренекле әсәре – “Өч аршын җир” повесте хакас теленә тәрҗемә ителде һәм басылып чыкты;
- Татарстан һәм Россия театрлары репертуарына язучының «Өч аршын җир» (Яр Чаллы дәүләт татар драма театры, А. М. Топанов исемендәге хакас милли драма театры), “Кар астында кайнар чишмә” (А. Мөбәрәков исемендәге Сибай башкорт дәүләт драма театры, Әлмәт татар дәүләт драма театры), “Ефәк баулы былбыл кош” (К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры), “Югалган көн” (Г. Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры) пьесалары кире кайтты;
- татар театрларында А. Гыйләҗевнең прозасы: “Оҗмах капкасы” (“Җомга көн, кич белән” әсәре буенча, Әлмәт татар дәүләт драма театры), “Яра” (шул ук исемдәге повесть буенча, Т. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры), “Әтәч менгән читәнгә” (шул ук исемдәге повесть буенча, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры) әсәрләре сәхнәләштерелде;
- “Балта кем кулында?” романын рус теленә тәрҗемә итү буенча эш башланды.

А. Гыйләҗевнең әдәби мирасы чын мәгънәсендә вакыт сынавын үтте дияргә була. XX йөзнең икенче яртысы — татар әдәбияты үсешендә иң әһәмиятле дәверләрнең берсе, тормыш-яшәешнең һәр өлкәсендә барган бөек үзгәрешләр вакыты. Шул вакытта А. Гыйләҗев кебек кин кырлы шәхесләр, әлеге чорның иҗтимагый-мәдәни тормышында яңа дәвер хасил итеп, милләтнең намусы һәм пакь йөзе булдылар. Татар халкы үзенең бөек улын хәтерли һәм ярата, һичшиксез, аның иҗади мирасын яңа буын укучыларга да җиткерәчәк.

***Миләүшә Хәбетдинова,***
***филология фәннәре кандидаты,***
***Казан шәһәре***



## УЧИТЕЛЬ, НАСТАВНИК, ГРАЖДАНИН

***В Кызылорде в областном музыкально-драматическом театре имени Н. Бекежанова в субботу 17 марта прошел вечер памяти, посвященный 100-летию заслуженного учителя Казахской ССР Нагимы Абдуловны Ахмадеевой.***

Немало теплых слов было сказано о Нагиме Абдуловне. Заместитель акима области Руслан Рустемов подчеркнул, что она была настоящим патриотом Казахстана и внесла весомый вклад в развитие образования. В характере Н. Ахмадеевой сочетались решительность, независимость и доброта.

Как отметила руководитель отдела центра «Рухани жаңғыру» Алима Абдыкалыкова, Нагима Абдуловна была профессионалом, энтузиастом, любила свое дело. Ее жизнь – это служение государству, учителю, ученику. Она уважительно относилась к людям.

Своими воспоминаниями о Нагиме Ахмадеевой поделились директор средней школы № 112 Асылбек Сеилханов, ветераны образования Рафикат Хафизов, Марк Подольский и другие.

Организаторы вечера – представители татарского этнокультурного объединения на сцене воссоздали эпизоды из жизни Нагимы Ахмадеевой. К примеру, в 1950-м году на женщину была возложенна персональная ответственность – контролировать строительство школы. В то время в городе остро ощущался дефицит учебных заведений и было принято решение в залинейной части областного центра построить школу. Зрители увидели, как Нагима Абдуловна встретилась с первым секретарем обкома партии Сафаром Бектелеевым и вторым секретарем Баймаханом Ибрагимовым. На вопрос, справится ли она со столь важным поручением, Нагиа Ахмадеева уверенно ответила: «Партия поручит – справлюсь».

Потом зрители увидели, как открывалась средняя школа № 112 имени XIX партсъезда.

Другая мизансцена была о том, как проходил митинг, посвященный открытию во дворе учебного заведения памятника Герою Советского Союза Алие Молдагулово. В этой церемонии, помимо педагогов и учащихся, приняли участие второй секретарь горкома партии Аблай Айдосов, участник Великой Отечественной войны, первый секретарь горкома партии Владимир Ковалев.

Светлый образ Нагимы Ахмадеевой жив в сердцах кызылординцев. И они рассказывают об этой женщине, самоотверженно трудившейся на благо Отечества, подрастающему поколению, чтобы молодежи было с кого брать пример. Юноши и девушки многое узнали о Нагиме Абдуловне. Она родилась в Петропавловске в 1918-м году в семье рабочего-грузчика. Получила высшее педагогическое образование в Семипалатинске, став учителем биологии и химии. В 1945-м году в связи с переводом ее мужа на работу переехала со всей семьей в Кзыл-Орду. Директором






проработала 26 лет. В 1978-м году ей были присвоены звания «Персональный пенсионер Казахской ССР» и «Почетный гражданин Кзыл-Орды». В 1991-м году она основала татарский общественно-культурный центр, который работает уже более 26 лет.

Группе кызылординцев, в свое время работавшей с ней, вручен памятный юбилейный нагрудной знак к 100-летию со дня рождения Нагимы Ахмадеевой.

Говорят, человек жив до тех пор, пока о нем помнят люди. Нагима Ахмадеева запомнилась многим, как профессионал, стремившейся в работе к высокому качеству, как опытный руководитель и организатор, любящая мать, благородная бабушка, заботливый товарищ и преданный друг.

***Руслан Абуталипов, г. Кызылорда***




8 29 '02










**Я ЛЮБЛЮ ТЕБЯ, КОКШЕТАУ!**

*Зрелищный, динамичный гала-концерт на трех языках «Мин яратам сине, Кокшетау», прошедший в «Қоғамдық келісім», посвященный родному городу, в третий раз собрал полный зал.*

Пролог «Летим к мечте» под шлягер «На большом воздушном шаре» дал ясно понять, что скучать не придется. Организатор мероприятия -«Объединение татар и башкир Акмолинской области» привлек к участию юные таланты в разных жанрах исполнения и своих непревзойденных асов в искусстве вокала: мастерство показали учащиеся детской музыкальной школы, колледжей им. Биржан сала, им. Акана серэ, активисты этнокультурных объединений.

До чего дошел прогресс: еще не успели отгреметь последние аплодисменты, а на I*nstagram* некоторых информагентств уже обсуждали исполнение лауреатов XVII международного фестиваля 2016 года, солисток ансамбля «Галиябану», которым дирижировал сам председатель. Об этом активисты молодежного крыла центра активно делились друг с другом. На этот раз абики реально отличились, исполнив татарскую песню в модном стиле битбокс, чем и заработали одобрительные возгласы молодежи. Казалось, сбросив с себя лет эдак по 40, и в дуэтах, и в квартете, они не отставали от студентов колледжа культуры им. Акана серэ под руководством Галины Рыбаковой, создавшей концепцию мероприятия. В такие минуты всеобщего позитива вспоминаешь слова- эпиграф к празднику нашего знаменитого земляка Ибрагима







Салахова: «Нет земли красивее земли кокшетауской, нет людей милее кокшетауцев».

Всеобщее восхищение вызвала будущая эстрадная элита области - студенты колледжа им. Биржан сала Ринат Нурмухан, Мергали Хамит, Жаркын Серикжан (концертмейстер Чингиз Елеманов), исполнившие песни из репертуара знаменитого Ермека Серкебаева и итальянскую «На качелях». Юная пианистка Индира Хабибуллина и дебютантка фестиваля Адия Исаканова трогательно сыграли на фортепиано произведения композиторов-классиков Д. Шостаковича и Э. Грига.

На ура встретили участницу международного конкурса по художественной гимнастике Жасмину Исаканову, вошедшую в тройку лучших от нашей области. Оказавшись в объятиях мелодии саксофона в исполнении Шамиля Салимзянова, зрители были рады вновь встрече с юным артистом, который неделю назад вернулся с международного конкурса из Италии. Волну подхватила Динара Сарсекеева, голос которой, отметим, с каждым выступлением набирает свою мощь и красоту. «Пусть на *земле*, мой Казахстан прекрасный, Цветут сады, смеются дети! *Не будет тесно людям разных наций*! Мы самые счастливые на свете!»,- с гордостью читают ведущие.

А душевные звуки домбры Рината Айтенова и Асета Ермана не оставили равнодушными сидящих в зале, продолжившись попурри, в котором под громкие аплодисменты звучали кавказские мотивы, знакомые всем мелодии из популярных казахских и русских песен. Выступление молодежной танцевальной группы «Яшьлек» в постановке Эльмиры Габдулкафеевой зарядили зрителей на веселые пляски.

На позитивной ноте и завершился объединяющий разные поколения людей концерт, посвященный любви родному Кокшетау. Зрители отметили высокий уровень проведения. В перспективе взять высокую планку: провести следующий на уровне республики. В такие минуты единения, общей радости и дружбы особо верится в благополучие и процветание нашего единого шанырака - Республики Казахстан.

За вклад в развитие татарской культуры участников отметили благодарственными письмами, памятными подарками Казахстанского конгресса татар и башкир, а также центра татарской культуры.

***Вероника Бурда, Кокшетау.***
(Акмолинская правда № 40 от 7.04.2018. Фото пресс-службы «Қоғамдық келісім»).




Нет земли красивее земли Кокшетауской
Нет людей милее кокшетауцев
И. Н. Салахов


"Біздің дамуымыздың кепілі -
тұрақтылық пен
Қазақстан халқының бірлігі"

***Казакъстан татарлары һәм башкортлары Конгрессы оешмаларының иҗтимагый- мәдәни тормышы фотографияләрдә***







РУХАНИ
ЖАҢҒЫРУ








***Дорогие читатели газеты!***

***Ваши материалы для помещения в газете следует отправлять в программе Word по электронной почте в адрес [griftim@mail.ru](mailto:griftim@mail.ru).***

***Напоминаем, что редакция не рецензирует материалы, а также не выражает публично свое отношение к содержанию и форме представленных материалов.***


| **ГАЗЕТА “ФИКЕР” № 4 (117), 2018 год. Электронная версия. Орган Казахстанского конгресса татар и башкир** | |
|---|---|
| Главный редактор Г.Т.Хайруллин Компрьютерная верстка Р.Р.Наратов | Свидетельство о постановке на учет средств массовой информации №13715 от 26 июня 2013 года. Выдано Комитетом архивов Министерства культуры и информации РК |